Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Аппак авыл Советы

КАРАРЫ

16 июль 2024 ел №103

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл Советының 2013 елның 25 ноябрендәге 85 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл җирлеге Уставының 28 статьясы нигезендә

Аппак авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл Советының 2013 елның 25 ноябрендәге 85 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 134 номерлы, 2015 елның 5 маендагы 155 номерлы, 2020 елның 12 маендагы 107 номерлы, 2020 елның 18 ноябрендәге 5 номерлы, 2023 елның 14 декабрендәге 91 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 пунктка түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:

«гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләренә (территорияләргә) карата казна, бюджет һәм автоном учреждениеләр («урам-юл челтәре», «территорияне төзекләндерү» куллану төрләрен кертеп»).»;

1.2. 5 пунктның алтынчы абзацын җиденче абзац дип санарга.

2. Әлеге карарны "Альметьевский вестник" газетасында бастырып чыгарырга, Әлмәт районы, Аппак авылы, Тынычлык урамы, 71 нче йорт; Илтән-Бота авылы, Совет урамы, 71 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында игълан итәргә, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2024 елның 1 январеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Аппак авыл
җирлеге башлыгы В.Н. Горбунова